СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ РОМОДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с. Ромодан **КАРАР**

05.07.2022 №26

**Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге советының 15.04.2016 № 25 нче «Ромодан авыл җирлегемуниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр, шулай ук муниципаль берәмлектә муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында (19.11.2018ел №92,25.06.2021ел №17дәге үзгәрешләр белән.)**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2022 ел, № 90-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә,

**Ромодан авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Ромодан авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Ромодан авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Алексеевск муниципаль районы Бутлерово

авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге 25 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, 8 пунктның 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«3) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активларын, цифрлы валютаны хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән, алыш-биреш башкарылган алыш-биреш чыганакларыннан артып китсә.».

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә һәмТатарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге территориясендә игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Ромодан авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И. А. Чекалина**